**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур.,19

Тел./факс: +7(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**31 май 2023 ел** **№ 76**

## Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пунктына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына нигезләнеп, Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы:

1. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр закон буенча да, васыять буенча варислар да булмаса, яки варисларның берсенең дә мирас алырга хокукы булмаса, яки варислар мирас алудан читләштерелсә, яки варисларның берсе дә мирасны кабул итеп алмаса, яки аларның барысы да мирас алудан баш тартса, һәм аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;

2) салым түләүче гражданның стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада яшәве;

3) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән өч еллык срокның тәмамлануы;

4) гамәлдән чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең 2019 елның 18 ноябрендәге 195 номерлы «Җирле салымнар буенча бурычны, шулай ук пенялар, штрафлар буенча бурычларны түләтүне өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының

рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә..

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм үз көчен 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе, Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина